**КАРАР**

**28 ноябрь, 2020 ел** **№16**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кнә-Юмья авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 28 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кнә-Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Иске Кнә-Юмья авылының Мәскәү урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Иске Кнә-Юмья авылының Мәскәү урамына балалар һәм спорт инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Иске Кнә-Юмья авылының Мәскәү урамына тышкы күзәтү видеокамералары сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- яктырткычлар, энергия саклаучы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 266 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 136 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан136 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кнә-Юмья авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, күп балалы гаиләләр һәм туендыручысын югалткан гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кнә-Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

3.

- Иске Кнә-Юмья авылының Мәскәү урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Иске Кнә-Юмья авылының Мәскәү урамына балалар һәм спорт инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Иске Кнә-Юмья авылының Мәскәү урамына тышкы күзәтү видеокамералары сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- яктырткычлар, энергия саклаучы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип таныргa.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Нырья
авыл җирлеге башлыгы В.В.Васильев